| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 31 август № 605

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2016 ел, 14 март, 138 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2016 ел, 14 март, 138 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 23 июнь, 428 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2016 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга савым сыерларын, кәҗәләрне һәм ана кәҗәләрне карап тоту буенча чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр бирү тәртибе»;

әлеге карар белән расланган «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү өчен каралган 2016 елга финанслау күләмнәрен бүлүдә:

таблицага түбәндәге эчтәлекле 48 пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 48. | шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга савым сыерларын, кәҗәләрне һәм ана кәҗәләрне карап тоту буенча чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр | 362 048,0»; |

«Барлыгы» юлында «6 126 659,9» саннарын «6 488 707,9» саннарына алмаштырырга;

күрсәтелгән карарга 2016 елда шәхси ярдәмче хуҗалыгы булган гражданнарга савым сыерларын, кәҗәләрне һәм ана кәҗәләрне карап тоту буенча чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруга субсидияләр бирү тәртибен өстәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков